СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

27.05.2024 № 46/2

На №__________ от______________

## КАРАР

### Район территориясендә яшь буынга гражданлык һәм патриотик тәрбия бирү турында

«Район территориясендә яшь буынга гражданлык һәм патриотик тәрбия бирү турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, балалар һәм яшүсмерләрне гражданлык һәм патриотик тәрбияләүнең зур социаль әһәмиятен исәпкә алып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны исәпкә алырга.
2. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә һәм «Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениясенә яшьләрнең рухи юнәлешләрен һәм гражданлык-патриотик аңы дәрәҗәсен өйрәнү буенча эшне дәвам итәргә.
3. Район Башкарма комитетына, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре белән берлектә, югары сыйныф укучыларын 2024 елда Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакыру буенча эшне дәвам итәргә.
4. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы баш редакторына әлеге тема кысаларында үткәрелгән төп чараларны район газетасында яктыртырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинга йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров